*“ 2 татар мәктәбенә 110 яшь”*

**Директорларның директоры**

*Хөрмәтле укытучым, директорыбыз Сөләйман абый Кузюровның якты истәлегенә багышлыйм.*




Директор С.М.Кузюров (уртада) укытучылар һәм 1951-1952 нче елгы чыгарылыш чыгарылыш класс укучылары белән

Теләсә кайсы коллективта, кечкенәме ул, зурмы, эшнең уңышы җитәкчедән башлана. Класста класс җитәкчесеннән, мәктәптә директордан, завучтан...

Безнең Сөләйман Мотыйгуллович үзе гади, әмма буй җитмәслек биеклектә торучы кеше иде.Аның хакында нинди сүздәр әйтсәм дә аз булыр кебек. Мин – Сөләйман абыйның укучысы, аның белән озак еллар эшләгән укытучы да. Көннәрнең иң авырын да, шатлыклысын да бер коллективта кичердек. Онытылмаслык булып, йөрәккә уелып калганы Сөләйман абыйны Бөек Ватан сугышына озату булды. Бүгенгедәй күз алдымда, илебез өчен иң авыр булган 1942 елның язы иде. Укучылар һәм укытучылар мәктәп ишегалдына чыгып тезелдек. Каршыбызда җиңелчә киенгән, иңенә зур булмаган биштәрен күтәргән Сөләйман абый басып тора. Йөзендә җитдилек тә, эчке дулкынлану да, көчле ихтыяр да бар. Ул, соңгы сүзе итеп, безгә классларга керергә һәм дәресләрне дәвам итәргә кушты.

Дәһшәтле сугышның озын-озак юлларын үтте Сөләйман абый. Берлинга барып җитте. Немец-фашистларны җиңү билгесе итеп, Рейхстаг стенасына кадак белән чокып үз исемен язып кайтты. Сөләйман абыйның, орден-медальләрен чыңлатып, сугыштан исән-сау кайтуы безнең өчен әйтеп бетергесез шатлык булды.

М. Вахитов исемендәге урта мәктәптә без Сөләйман Мотыйгулловичтан химия, биология фәннәрен өйрәндек. Аның дәресләре

хәтеребезгә онытылмаслык булып кереп калды. Ул искиткеч белемле, гаять таләпчән укытучы иде. Сөйләгәндә сүзнең мәгънәсенә басым ясый, һәр әйткән сүзе урынлы, куйган таләбе хаклы иде аның. Дәресләре гаҗәеп эшлекле үтә иде. Сөләйман абый укучыларга төпле белем бирде, үз фәненә олы мәхәббәт тудыра алды. Без, Сөләйман абыйның укучылары, югары уку йортлары тәмамлап, туган мәктәбебездә укытучы булдык. Мәктәпнең завучы, директоры буларак Сөләйман Мотыйгуллович аталарча кайгыртучан булды. Аның тормышында мәктәп һәрвакыт беренче урында иде, шулай булып калды да. Без дә аның кебек, балаларны яратып, күңел биреп эшләргә өйрәндек. Сөләйман абый олы хөрмәткә лаек директор, сирәк очрый торган сәләтле, туры сүзле, гадел кеше иде. Районда, шәһәребездә, республикада, бигрәк тә ата-аналар, халык арасында абруйлы шәхес булды. Иң әһәмиятлесе

– укыту-тәрбия эшен Ватаныбыз таләпләре югарылыгында куя алды. Эшебездәге һәр уңышка ихлас күңелдән куанды, намуслы, эшчән, иҗади эшләүче фидакарь укытучылар хезмәтенә зур ихтирам белән карады. Аннан ишеткән һәрбер җылы мактау сүзе орден-медальләрдән дә кадерлерәк була иде.

Сөләйман Мотыйгуллович ялкаулыкны, хөрдәләүне, күрсәтер өчен генә эшләүне, ялагайлыкны һәм әләкчелекне җаны-тәне белән сөймәде, андыйларны үз янына җыймады. Эшендә һәрчак коллективка таянды. Директор коллективтан бер башка югарырак торырга тиеш, диләр. Ул берничә мәртәбә югарырак иде дисәм дә арттыру булмас.

Безнең укыту авыр елларга туры килде. Кыенлыклар да җитәрлек иде. Баштан сыйпап гына тормадылар. Әмма Сөләйман Мотыйгуллович бервакытта да ачу куып, эшкә зарар китермәде.

Директор буларак, бездә укып чыккан балаларның тормышта ничек урнашуларын да күзәтеп барырга вакыт тапты ул. Аларның уңышлары өчен ихлас шатлана белде. Мәсәлән, укучыбыз Марс Дәүләтшинны бер дә күз уңыннан төшермәде. Алар бер анага өч бала үстеләр, бездә укыдылар. Марс аеруча сәләтле, уңган иде. Соңыннан Марс Мөбәрәкович шәһәребез җитәкчелегендә бик җаваплы, югары урыннарда эшләде. Әмма бервакытта да укыган мәктәбен онытмады. “Башлы егет, талантлы, эшчән”, - дип сөенә иде Сөләйман Мотыйгуллович. Күп балалы гаиләләрдә үскән укучыларга аеруча игътибарлы иде ул. Шаянрак, “усалрак” укучыларга карата исә үзенчә бер карашы-фикере бар иде. “Сез аларны үзегездән читләштермәгез, сәләтен ачарга тырышыгыз, яраткан шөгылен үстерергә булышыгыз. Андый укучы сезне гомере буе онытмас”, – дип өйрәтә иде ул укытучыларны. Аның бу киңәшләренең ничек дөрес булганына без үз тәҗрибәбез аша инандык.

Сөләйман Мотыйгуллович үзе дә безнең белән бергә үсте, һаман күтәрелде. Татарстанның атказанган укытучысы булды. Мәктәп җитәкчеләре алышынып торуга карамастан, без, аның шәкертләре, һәрвакыт ихлас күңелдән эшләдек. Сөләйман Мотыйгуллович башлаган гүзәл традицияне ахыргача намус белән дәвам иттек дип горурланып әйтә алабыз. Ул җитәкчелек иткән онытылмас еллар (1942-1962) - мәктәп еллары аерым бер урында. Сөләйман абый Кузюровны зурлап, директорларның директоры дип йөртә идек. Бу һич арттырусыз шулай. Моны минем белән бергә эшләгән хөрмәтле хезмәттәшләрем дә раслар.



*Мәктәп директоры С.М. Кузюров укытучылар коллективы арасында*

Директорыбыз үрнәк гаилә башлыгы иде. Шактый җаваплы һөнәр иясе булган Наһар апа белән алар дүрт бала тәрбияләп үстерделәр, һәммәсенә югары белем алырга ярдәм иттеләр. Балалары үзләре кебек үк халкыбызга тугрылыклы хезмәт итәләр.

Сөләйман Мотыйгуллович тормышны өзелеп яратты. Аның белән мәңгегә хушлашсак та, ул күңелләребездә яши. Андый кешеләр үлемсез.

Анна Ивановна Солтанова – Бустерякова, 93 яшьлек ветеран укытучы.